**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об автомобильных дорогах и о дорожной деятельности на территории Республики Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
21 апреля 2022 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 3 августа 2009 года № 43-ЗРТ «Об автомобильных дорогах и о дорожной деятельности на территории Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 7 – 8 (III часть); 2011, № 4 (I часть); 2012, № 1; 2013, № 4 (I часть); 2015, № 4, № 10 (I часть); 2016, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 25 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 29 (часть I); 2019, № 19 (часть I); 2020, № 94 (часть I); 2021, № 77 (часть I) следующие изменения:

1) в абзаце первом преамбулы слова «Федеральным законом от 6 октября 1999 года № 184-ФЗ «Об общих принципах организации законодательных (представительных) и исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации» заменить словами «Федеральным законом от 21 декабря 2021 года № 414-ФЗ «Об общих принципах организации публичной власти в субъектах Российской Федерации»;

2) пункт 5 статьи 12 изложить в следующей редакции:
«5) информационное обеспечение пользователей автомобильными дорогами общего пользования регионального значения, в том числе посредством системы контроля за формированием и использованием средств дорожных фондов;»;

3) пункт 12 статьи 13 дополнить словами «, в том числе посредством системы контроля за формированием и использованием средств дорожных фондов»;

4) в статье $13^1$:
а) часть 2 дополнить предложением следующего содержания: «В таком случае составление актов контрольных (надзорных) мероприятий и выдача по их

результатам предписаний осуществляются инспекторами указанных государственных, муниципальных учреждений.»;

б) дополнить частью $2^1$ следующего содержания:

«$2^1$. Квалификационные требования для замещения должности инспектора в государственных и муниципальных учреждениях, указанных в части 2 настоящей статьи, устанавливаются нормативным правовым актом Кабинета Министров Республики Татарстан, муниципальными нормативными правовыми актами с учетом положений Федерального закона от 31 июля 2020 года № 248-ФЗ «О государственном контроле (надзоре) и муниципальном контроле в Российской Федерации».».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования, за исключением положений, для которых настоящей статьей установлены иные сроки вступления их в силу.

2. Пункт 1 статьи 1 настоящего Закона вступает в силу с 1 января 2023 года.

3. Пункты 2 и 3 статьи 1 настоящего Закона вступают в силу с 1 марта 2023 года.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
27 апреля 2022 года
№ 19-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбуланың беренче абзацында «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

2) 12 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5) региональ әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан файдаланучыларны мәгълүмати тәэмин итү, шул исәптән юл фондлары акчаларын булдыруны һәм алардан файдалануны тикшереп тору системасы ярдәмендә;»;

3) 13 статьяның 12 пунктында «, шул исәптән юл фондлары акчаларын булдыруны һәм алардан файдалануны тикшереп тору системасы ярдәмендә» сүзләрен өстәргә;

4) $13^{1}$ статьяда:

а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Мондый очракта тикшереп тору (күзәтчелек итү) чаралары актларын төзү һәм аларның нәтиҗәләре буенча күрсәтмәләр бирү күрсәтелгән дәүләт учреждениеләре, муниципаль учреждениеләр инспекторлары тарафыннан башкарыла.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $2^{1}$ өлеш өстәргә:

«$2^{1}$. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән дәүләт учреждениеләрендә һәм муниципаль учреждениеләрдә инспектор вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләре, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый акты, муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнә.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге статьяда аларның үз көченә керүенең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 һәм 3 пунктлары 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты | Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 27 апрель
№ 19-ТРЗ